**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«25» март 2024 ел № 787

Комплексслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзү турында һәм комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе эше регламентын раслау хакында

«Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы, «Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләре урынын килештерү өчен төзелә торган килештерү комиссиясе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 20 мартындагы 177 номерлы карары, «Комплекслы кадастр эшләрен оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 31 мартындагы 237 номерлы карарына үзгәрешләр кетрү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 11 июнендәге 551 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе төзергә һәм әлеге карарга 1 кушымта нигезендә составын расларга.

2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке, Борды, Князево, Күзкәй, Кече Шилнә, Мәләкәс, Мусабай-Завод, Түбән Суыксу, Шилнәбаш авыл җирлекләре территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе эше регламентын әлеге карарга 2 кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 мартындагы 787 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елда Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Хәбибуллин А.Р. | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Галимова Г.Ә. | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| Нәдершин А.Н. | Тукай муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе |
| Ихсанов Ф.Г. | Төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча башлык ярдәмчесе |
| Киямов А.А. | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары |
| Габделхаков А.Р. | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының кадастр мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы |
| Мурина И.В. | СРО Поволжье вәкиле |
| Барсукова А.Н. | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлеге башлыгы |
| Яппаров Р.Б. | «БТИ РТ» АҖ Яр Чаллы филиалының Тукай һәм Актаныш бүлекчәләре җитәкчесе |
| Костина И.А. | «БТИ РТ» АҖ Яр Чаллы филиалы җитәкчесе урынбасары |
| Валеева В.А. | Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге башлыгы |
| Әбделманова Р.Н. | Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башлыгы |
| Вилданов И.М. | Тукай муниципаль районы Князево авыл җирлеге башлыгы |
| Гәрәев Э.Р. | Тукай муниципаль районы Күзкәй авыл җирлеге башлыгы |
| Даутов А.Г. | Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге башлыгы |
| Васильев Ю.П. | Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге башлыгы |
| Хөсәинова З.З. | Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге башлыгы |
| Вәзеева Ф.А. | Тукай муниципаль районы Түбән Суыксу авыл җирлеге башлыгы |
| Чекушкова О.А. | Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге башлыгы |

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 25 мартындагы 787 номерлы карарына 1 кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясенең эш регламенты

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясе эшенең әлеге регламенты (алга таба - регламент) «Кадастр эшчәнлеге турында» 24.07.2007 ел, № 221-ФЗ Федераль закон нигезендә эшләнгән (алга таба – 221-ФЗ номерлы Федераль закон).

1.2. Әлеге регламент комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү буенча килештерү комиссиясенең составын, вәкаләтләрен һәм эш тәртибен билгели (алга таба – килештерү комиссиясе).

1.3. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге норматив хокукый актларына, шулай ук регламентка таяна.

1.4. Килештерү комиссиясе эшенең максаты булып комплекслы кадастр эшләрен башкарганда җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү тора. Чикләрнең урнашу урынын килештерү 221-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чикләренең урнашуы мәҗбүри килештерелергә тиешле җир кишәрлекләренә карата үткәрелә.

## II. Килештерү комиссиясенең вәкаләтләре

2. Килештерү комиссиясенең вәкаләтләренә керә:

2.1. Түбәндәге хокук буенча янәшә җир кишәрлекләренә ия булган кызыксынган затларның җир кишәрлекләре чикләренең урнашуына карата каршылыкларны карау:

1) милек (дәүләт яки муниципаль милектә булган мондый янәшә җир кишәрлекләре гражданнарга гомерлеккә мирас итеп алынган милеккә, даими (сроксыз) файдалануга, яисә дәүләт яки муниципаль учреждениеләр булмаган юридик затларга, яисә казна предприятиеләренә даими (сроксыз) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

2) гомерлеккә мирас итеп алынган милек;

3) даими (сроксыз) файдалану (әгәр мондый янәшә җир кишәрлекләре дәүләт яки муниципаль учреждениеләргә, казна предприятиеләренә, дәүләт хакимияте

органнарына яки җирле үзидарә органнарына даими (сроксыз) файдалануга бирелгән очраклардан тыш);

4) аренда (әгәр мондый янәшә җир кишәрлекләре дәүләт яки муниципаль милектә булса һәм тиешле аренда шартнамәсе биш елдан артык вакытка төзелгән булса) (алга таба – кызыксынучылар);

2.2. Җир кишәрлекләренең чикләре урнашуга карата регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затларның каршылыкларын карау нәтиҗәләре турында, шул исәптән мондый каршылыклар нигезсез булган очракта территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка туры килмәве турында яки комплекслы кадастр эшләрен башкаручының мондый каршылыклар нигезендә территориянең карта-планын үзгәртү кирәклеге турында килештерү комиссиясенең бәяләмәсен әзерләү.

2.3. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын рәсмиләштерү.

2.4. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынган затларга җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсен суд тәртибендә хәл итү мөмкинлеген аңлату.

## III. Килештерү комиссиясе составы, килештерү комиссиясе әгъзаларының вәкаләтләре

3.1. Килештерү комиссиясе рәисе булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тора.

3.2. Килештерү комиссиясе рәисе:

3.2.1. Килештерү комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итә.

3.2.2. Килештерү комиссиясе эшчәнлеген планлаштыра, килештерү комиссиясе утырышларының көн тәртибен раслый.

3.2.3. Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибе мәсьәләләрен карауны оештыра.

3.2.4. Каралган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәрне тавыш бирүгә куя, тавыш бирүне һәм килештерү комиссиясе әгъзаларының тавышларын санауны оештыра, аларның тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели.

3.2.5. Килештерү комиссиясе исеменнән җибәрелгән запросларга, мөрәҗәгатьләргә һәм башка документларга кул куя.

3.3. Килештерү комиссиясе рәисе урынбасары рәис вәкаләтләрен ул булмаганда гамәлгә ашыра.

3.4. Килештерү комиссиясе секретаре:

3.4.1. Килештерү комиссиясе утырышларында карау өчен материаллар әзерләүне оештыра.

3.4.2. Килештерү комиссиясе утырышының көн тәртибе проектын төзи.

3.4.3. Килештерү комиссиясе әгъзаларына утырышның вакыты һәм урыны, утырышның көн тәртибе турында хәбәр итә, утырышка әзерләнгән материаллар белән таныштыра.

3.4.4. Килештерү комиссиясе утырышларының беркетмәләрен алып бара.

3.4.5. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында килештерү комиссиясе бәяләмәсен, комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актын әзерли.

3.4.6. Килештерү комиссиясе рәисе яки килештерү комиссиясе рәисе урынбасарының килештерү комиссиясе эшчәнлеге белән бәйле башка йөкләмәләрен үти.

3.5. Килештерү комиссиясе әгъзалары:

3.5.1. Килештерү комиссиясе рәисе йөкләмәсе нигезендә килештерү комиссиясе утырышларын әзерләүдә катнашалар.

3.5.2. Килештерү комиссиясе утырышларында катнашалар.

3.5.3. Утырышта булмаганда, каралган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма формада белдерәләр, ул утырышта игълан ителә һәм килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә теркәлә.

3.6. Утырышта кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, килештерү комиссиясе әгъзалары үз фикерләрен язма рәвештә әйтергә хокуклы, ул килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

## IV. Килештерү комиссиясенең эш тәртибе

4.1. Җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча комиссия утырышын уздыру турында хәбәр, шул исәптән территориянең карта-планы проектын әзерләүне тәмамлау турында хәбәрнамә, комплекслы кадастр эшләренә заказ бирүче тарафыннан, күрсәтелгән утырышны үткәрү көненә кадәр кимендә унбиш эш көне кала, комплекслы кадастр эшләрен башкару башлануы турында хәбәрнамәне бастырып чыгару, урнаштыру һәм җибәрү өчен Федераль законда билгеләнгән ысуллар белән бастырып чыгарыла, урнаштырыла һәм җибәрелә.

4.2. Территориянең карта-планы проекты комплекслы кадастр эшләре заказчысы тарафыннан 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 9 өлеше нигезендә килештерү комиссиясенә җибәрелә.

4.3. Килештерү комиссиясе түбәндге юллар белән теләсә кайсы затны территориянең карта-планы проекты белән таныштыруны тәэмин итә:

4.3.1. Мөрәҗәгать итүченең запросы нигезендә территориянең карта-планы проектын электрон документ рәвешендә җибәрү.

4.3.2. Килештерү комиссиясе урнашкан урын буенча документ формасында территориянең карта-планы проекты белән танышу мөмкинлеге бирү.

4.4. Килештерү комиссиясе утырышында территориянең карта-планы проекты тәкъдим ителә, комплекслы кадастр эшләрен башкару нәтиҗәләре, җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү тәртибе һәм килештерү комиссиясенең эш регламенты аңлатыла.

4.5. Регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынган затларның 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.1 статьясы 1 өлеше 1 һәм 2 пунктларында

күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең урнашуына карата каршылыклары җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү мәсьәләсе буенча килештерү комиссиясе утырышын уздыру турында хәбәр басылып чыккан көннән алып әлеге утырыш үткәрелгән көнгә кадәр, шулай ук килештерү комиссиясенең беренче утырышы уздырылганнан соң утыз биш эш көне дәвамында килештерү комиссиясенә язма рәвештә тапшырылырга мөмкин.

4.6. Җир кишәрлеге чикләренең урнашу урынына карата каршылыкларда 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 15 өлешендә күрсәтелгән мәгълүматлар булырга тиеш. Билгеләнгән сроктан соң килгән каршылыклар килештерү комиссиясе тарафыннан каралмый. Әлеге каршылыкларны караудан баш тарту турында хәбәрнамә кызыксынган затка әлеге каршылыклар килгән көннән алып өч эш көне эчендә җибәрелә.

4.7. Җир кишәрлеге чикләренең яки өлешләренең урнашу урынын килештергәндә мондый чикләрнең яки аларның өлешләренең урнашу урыны:

4.7.1. килештерелгән санала, әгәр җир кишәрлеге чикләренең яки чикләре өлешләренең урнашу урынына карата каршылыклар регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан бирелмәсә, шулай ук мондый чикләрнең яки чикләр өлешләренең урнашу урыны законлы көченә кергән суд акты нигезендә, шул исәптән җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсен карау белән бәйле рәвештә билгеләнгән очракта.

4.7.2. Бәхәсле санала, әгәр җир кишәрлеге чикләренең яки чикләре өлешләренең урнашу урынына карата каршылыклар регламентның 2.1 пунктында күрсәтелгән кызыксынучы затлар тарафыннан бирелсә, җир кишәрлеге чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсе суд тәртибендә хәл ителгән очраклардан тыш.

4.8. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының 20.04.2015 № 244 боерыгы белән расланган форма буенча килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе төзелә, шулай ук килештерү комиссиясенең җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынына карата каршылыкларны карау нәтиҗәләре турында түбәндәгеләрен үз эченә алган бәяләмәсе төзелә:

4.8.1. Кызыксынган затларның җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынына карата каршылыкларының кыскача эчтәлеге.

4.8.2. Килештерү комиссиясенә тапшырылган материаллар турында мәгълүмат.

4.8.3. Килештерү комиссиясенең җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршылыкларын карау нәтиҗәләре буенча, шул исәптән мондый каршылыклар нигезсез булган очракта территориянең карта-планы проектын үзгәртүнең максатка туры килмәве яки комплекслы кадастр эшләрен башкаручының мондый каршылыклар нигезендә территориянең карта-планын үзгәртү кирәклеге турында нәтиҗәләре.

4.9. Комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашу урынын килештерү актлары һәм килештерү комиссиясенең регламентның 2 бүлеге 2.2 һәм 2.3 пунктларында күрсәтелгән бәяләмәләре килештерү комиссиясе утырышы уздырылганнан соң биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль

районы Башкарма комитетында саклана торган документлар рәвешендә кәгазьдә рәсмиләштерелә.

4.10. Җир кишәрлекләре чикләре урнашу урынына карата кызыксынучы затларның каршылыклары нигезле булуга бәйле рәвештә, комплекслы кадастр эшләре башкаручы тарафынна территориянең карта-планы проектына үзгәрешләр кертү зарурлыгы турында килештерү комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән очракта, беркетмә һәм бәяләмә имзаланганнан соң өч эш көне эчендә комплекслы кадастр эшләре башкаручыга җибәрелә.

4.11. Территориянең карта-планы проекты соңгы редакциядә комплекслы кадастр эшләрен башкаручы тарафыннан килештерү комиссиясе адресына регламентның 4.10 пунктында каралган документлар килгән көннән алып ун эш көне эчендә җибәрелә.

4.12. 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясы 14 өлешендә каралган каршылыкларны тапшыру вакыты тәмамланганнан соң егерме эш көне эчендә килештерү комиссиясе комплекслы кадастр эшләре заказчысына комплекслы кадастр эшләре башкаручы тарафыннан рәсмиләштерелгән соңгы редакциядәге территориянең карта-планы проектын һәм аны раслау өчен кирәкле килештерү комиссиясе утырышы материалларын раслау өчен җибәрә.

4.13. Килештерү комиссиясе утырышлары кирәк булганда үткәрелә.

4.14. Килештерү комиссиясе әгъзаларының яртысыннан артыгы утырышта катнашса, килештерү комиссиясе утырышы хокуклы дип санала.

4.15. Килештерү комиссиясе карарлары утырышта катнашучы килештерү комиссиясе әгъзалары санының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Килештерү комиссиясе әгъзалары тавышлары тигез булганда, килештерү комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч була.

## V. Йомгаклау нигезләмәләре

5.1. 221-ФЗ номерлы Федераль законның 42.10 статьясында каралган комплекслы кадастр эшләре башкарылган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урынын килештерү нәтиҗәсендә җайга салынмаган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсләре комплекслы кадастр эшләрен башкарганда чикләрнең урнашуын килештерү акты рәсмиләштерелгәннән соң суд тәртибендә хәл ителә.

5.2. Килештерү комиссиясенең бәяләмәсе булу яки булмау комплекслы кадастр эшләре башкарылган җир кишәрлекләре чикләренең урнашу урыны турында җир бәхәсләрен хәл итү өчен судка мөрәҗәгать итүгә комачауламый.